СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 1-5 «12» январь 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 18 декабрендәге 48 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 18 декабрендәге 2-4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендәге 2-30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә нигезендә статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2016 елның 28 февраленә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә

катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хакимият чикләрендә халыкка электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, канализация, ягулык белән тәэмин итүне оештыру.
Ямаш авылында су алу башнясын койма белән тотып алу - 16,0 мең сум.

- Җирлек халкы өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын оештыру, шул исәптән гражданнарның җәмәгать су объектларына һәм аларның ярларына бушлай керүен тәэмин итү:
Ямаш авылында чишмәләрне төзекләндерү - 13,0 мең сум.

- Ял вакытын оештыру һәм торак пунктларында мәдәни оешмалар хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру:
Юкәче, Иске Мочалкино, Яңа Мочалкино авылында авыл клубларын ремонтлау - 44,8 мең сум.

- - Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Шәдче торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:
Муса Җәлил урамы – 250 м.
Мәктәп урамы – 1100 м.
Вахит торак пунктында:
Татарстан урамы – 300 м.
Габдулла Тукай урамы – 400 м.
Вак таш өстәү, грейдер белән тигезләү - 68,6 мең сум

«Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Башлыгы В. В. Шрыковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.В.Шрыков /